КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 августа г.Казань № 635

2018 елда паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган бүтән бюджетара трансфертларны файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2018 елда Россия Федерациясе резерв фондының бюджет ассигнованиеләре исәбенә паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү турында» 2018 ел, 1 март, 207 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елда паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган бүтән бюджетара трансфертларны файдалану тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына:

өлкәннәргә һәм балаларга паллиатив медицина ярдәмен күрсәтү мониторингын үткәрүне тәэмин итәргә;

өйдә паллиатив медицина ярдәмен күрсәткәндә медицина әйберләрен куллану тәртибен эшләргә һәм расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 3 август, 635 нче
карары белән расланды

2018 елда паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган бүтән бюджетара трансфертларны файдалану тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2018 елда паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны (алга таба – акча) файдалану механизмын билгели.

2. Акча Татарстан Республикасы бюджетының паллиатив медицина ярдәмен үстерү белән бәйле чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә юнәлдереләләр:

кирәкле дару препаратлары (авыртуны баса торганнарын кертеп) белән тәэмин итүгә;

өлкәннәргә һәм балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтү тәртибе нигезендә паллиатив медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларын медицина әйберләре белән тәэмин итү, шул исәптән өйдә файдалану өчен.

3. Акчаны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тота.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә гражданнарга паллиатив медицина ярдәме күрсәтү өчен дару препаратлары һәм медицина әйберләре сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләре) төзи.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән бүтән бюджетара трансфертлар килү турында мәгълүмат алганнан соң соңгысына билгеләнгән тәртиптә финанслауның чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерүгә чыгым тәртибен тапшыра.

6. Финанслауның җиткерелгән күләмнәре чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең акча килү һәм дәүләт заказын урнаштыру нәтиҗәләре турында хәбәрнамәләре нигезендә әлеге акчаны дәүләт контрактлары (шартнамәләре) төзелгән оешмаларга күчерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларга финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып бүтән бюджетара трансфертлар торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра:

а) ай саен – бүтән бюджетара трансфертлардан файдалану турында оператив мәгълүмат нигезендә хисап чоры тәмамланганнан соң өченче эш көненнән дә соңга калмыйча (хисап аеннан соң килүче айның беренче көнендә торышы);

б) квартал саен – хисап чоры тәмамланганнан соң 25 календарь көненнән дә соңга калмыйча һәм ел өчен – бүтән бюджетара трансфертлардан файдалану турында тиешенчә квартал һәм еллык хисап күрсәткечләреннән чыгып 2019 елның 2 апреленнән дә соңга калмыйча.

8. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.

9. Акчаны максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

10. Бүтән бюджетара трансфертларның 2019 елның 1 гыйнварына файдаланылмаган өлеше Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

___